**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге составына керүче Иске Ибрай торак пунктта**

2020 елда үзара салым кертү турында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2019 елның 28 ноябре № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Ибрай авыл җирлеге Иске Ибрай торак пунктында гражданнар җыены

Карар итте:

1. 2020 елда Аксубай муниципаль районының Иске Ибрай авыл җирлеге Иске Ибрай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 нче төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына һәм җирлек торак пунктлары чикләрендә юл эшчәнлеге:
- Кызыл Армия , Тукай, 1 нче Май, Үзәк, Җиңү, Бабил, Кызыл Чишмә, Яшьләр урамнарына грунт белән нигез салу.
- Иске Ибрай авылы юлларына вак таш сатып алу һәм түшәү.
- кышкы юлларны карап тоту.

2) Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итүне Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру:
   - Су суырткыч һәм скважина өчен комплектлаштыру җиһазлары сатып алу
3) авыл территориясен төзекләндерү тәртибен раслау, аны конторольдә тоту, авыл территориясендә төзекләндерү тәртибенә нигезләнеп оештыру
   - урамнарны яктыртуны оештыру буенча электр яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру

Иске Ибрай авыл җирлеге башлыгы М.Г.Минигулов